**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 20.05.2020** **№ 409**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты каршында иҗтимагый торак комиссиясе Нигезләмәсен һәм составын раслау турында**

Торак хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендәге мәсьәләләрне комплексы карау, гражданнарның торакка хокукларын үтәү максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексы, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә һәм «Авыл территорияләрен комплексы үстерү» федераль программасын гамәлгә ашыру максатларында, «Социаль ипотека» республика программасын гамәлгә ашыру һәм гражданнарга торак шартларын яхшыртуда ярдәм итү, авыл җирлегендә торак төзү һәм торак сатып алу өчен социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлекләренә кертелгәндә җәмәгать контролен һәм коррупцион хокук бозуларын профилактикалау чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты каршында иҗтимагый торак комиссиясе Нигезләмәсен (1 нче кушымта).

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты каршында иҗтимагый торак комиссиясе составын (килешү буенча) (2 нче кушымта).

2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип таныргa:

2015 елның 28 маендагы 1296 нчы номерлы «Иҗтимагый торак комиссиясен раслау турында»;

2015 елның 29 октябрендәге 1879 нчы номерлы «Биектау муниципаль районы иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында»;

2016 елның 12 февралендәге 195 нче номерлы «Биектау муниципаль районы иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында»;

2016 елның 07 ноябрендәге 2319 нчы номерлы «Иҗтимагый торак комиссиясенең яңа составын раслау турында»;

2018 елның 17 августындагы 1784 нче номерлы «Биектау муниципаль районы иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/

адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Ф.Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта
Расланды
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 маендагы 409 нчы номерлы карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты каршында иҗтимагый торак комиссиясе
Нигезләмәсе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе (алга таба - Комиссия) җирле үзидарә органнары вәкаләтләре нигезендә «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең торак хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне объектив, һәрьяклап карау максатыннан төзелгән даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

1.2. Торак комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясенең башка хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Әлеге Нигезләмә Комиссиянең вәкаләтләрен һәм ул хәл итә торган мәсьәләләр даирәсен билгели.

## 2. Иҗтимагый торак комиссиясен төзү һәм бетерү тәртибе

2.1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карар формасында Комиссияне төзү һәм бетерү турында карар кабул итә, шулай ук аның шәхси составынраслый.

2.2. Комиссия рәис, рәис урынбасары, җаваплы секретарь һәм Комиссия әгъзалары составында төзелә.

2.3. Иҗтимагый торак комиссиясе составына килештерү буенча җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, хезмәт коллективлары, профсоюзлар, ветераннар, яшьләр һәм башка иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә ала, шулай ук гражданнар җәмгыяте институтлары вәкилләрен кертү рөхсәт ителә.

2.4. Иҗтимагый торак комиссиясе составында кворум өчен әгъзалар так санда, әмма иҗтимагый торак комиссиясе составының 2/3нән ким булмаган өлеше булырга тиеш.

2.5. Комиссия составы 9 кешедән оеша.

## 3. Иҗтимагый торак комиссиясенең төп бурычлары, функцияләре һәм хокуклары

3.1. Комиссиянең төп бурычлары:

- муниципаль торак фондын исәпкә алу һәм бүлү мәсьәләләрендә җәмәгать контролен һәм хәбәрдарлыгын тәэмин итү;

- Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары компетенциясенә кертелгән торак законнары нигезендә гражданнарның торак хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү.

3.2. Комиссия компетенциясенә гражданнар һәм оешмалар тарафыннан түбәндәге мәсьәләләр буенча тапшырыла торган гаризаларны һәм документларны карау керә:

- социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында гражданнарны азкеремле дип тану;

- гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу;

- гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар исемлегеннән төшерү;

-социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар исәбендә торучы гражданнарга социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү;

-Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына тапшырыла торган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында торак төзүгә яисә сатып алуга социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлеген килештерү;

- «Социаль ипотека» программасы буенча торак алган һәм (яисә) исәпкә баскан гражданнарның исәпкә алу эшләренә үзгәрешләр кертү турында гаризалар карау;

- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына документларны алга таба җибәрү өчен «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү», «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасының шартларын үтәү яисә үтәмәү турындагы мәсьәләне карау;

- гражданнарны федераль льготниклар исемлегеннән төшереп калдыру;

- Биектау муниципаль районы муниципаль торак фондының хезмәт торак урыннарына мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә кую;

- хезмәт торак урынын наем шартнамәсе буенча бирү;

- Биектау муниципаль районы территориясендә коммерциячел наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү;

- муниципаль маневрлы торак фондының торак урыннарына мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә кую;

- муниципаль маневрлы торак фондының торак урыннарын бирү;

- яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү, шул исәптән аларны торак урыннарга мохтаҗ дип тану;

- күпбалалы гаиләләрнең аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү, шул исәптән аларны торак урыннарына мохтаҗ дип тану.

3.3. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- утырышларда үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне карарга;

- дәүләт хакимияте органнарыннан, Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләреннән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан Комиссия эше өчен кирәкле документларны, мәгълүматны, белешмә материалларны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

- гражданнар тарафыннан күрсәтелә торган документлардагы белешмәләрне тикшерү өчен эш төркемнәре төзергә;

- Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенә Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләргә;

- Комиссия бурычларыннан һәм вәкаләтләреннән килеп чыккан башка гамәлләрне тормышка ашырырга.

## 4. Иҗтимагый торак комиссиясенең эш тәртибе

4.1. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссиянең расланган составыннан кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы. Комиссия утырышын үткәрү турында карар Комиссия рәисе, ә ул булмаганда - рәис урынбасары тарафыннан кабул ителә. Кирәк булганда, Комиссия утырышына кызыксынучы затлар чакырылырга мөмкин.

4.2. Комиссия рәисе:

- Комиссия эше белән гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

- Комиссия компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча гражданнарны кабул итә;

- Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Комиссия рәисе булмаганда җитәкчелек итүне аның урынбасары башкара.

4.3. Комиссия секретаре:

- Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә материалларны тикшерүне һәм карауны оештыра;

- Комиссия утырышында каралырга тиешле мәсьәләләрне әзерли;

- Комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара;

- Комиссия карарлары проектларын әзерли;

- Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча барлык документлар комиссия секретаренда саклана.

4.4. Торак комиссиясе әгъзалары хокуклы:

а) торак комиссиясе утырышларында көн тәртибе мәсьәләләре буенча чыгыш ясарга;

б) торак комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карар белән килешмәгәндә, торак комиссиясе утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кушып беркетелергә тиешле аерым фикерне язма рәвештә бәян итәргә.

4.5. Комиссия утырышта катнашучы комиссия әгъзалары саныннан күпчелек тавыш белән карарны ачык тавыш бирү юлы белән кабул итә. Тавыш биргәндә комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия.

4.6.Кабул ителгән карар белән килешмәгән Комиссия әгъзасы үзенең аерым фикерен язмача бәян итәргә һәм аны комиссия утырышы беркетмәсенә кушарга мөмкин.

4.7. Утырышның көн тәртибе комиссиядә катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән раслана.

4.8. Комиссия утырышы кирәк булганда, тик кварталга кимендә 1 тапкыр уздырыла.

4.9. Комиссия әгъзасы нинди дә булса сәбәпләр аркасында утырышта катнаша алмаса (отпусктан, авырулардан, командировкадан тыш), ул бу хакта телефон элемтәсе аша Комиссия секретарена анда булмау сәбәпләрен күрсәтеп хәбәр итәргә тиеш.

4.10. Комиссия утырышында секретарь тарафыннан беркетмә алып барыла. Беркетмәдә Комиссиянең исеме, утырыш датасы, беркетмәнең номеры, Комиссия утырышында катнашучыларның саны һәм исемлеге, көн тәртибе чагылдырылырга тиеш.

Беркетмәгә тикшерелә торган мәсьәләләрнең кыскача эчтәлеге, алар буенча кабул ителгән карар, кирәк булганда, Комиссия әгъзаларының конкрет мәсьәләләр буенча аерым фикере кертелә.

Беркетмәгә Комиссия рәисе һәм секретаре имза куя. Комиссия беркетмәләре архив эше турындагы законнар нигезендә саклана.

Комиссия карары рекомендация характерында.

## 5. Иҗтимагый торак комиссияләренең җаваплылыгы

Иҗтимагый торак комиссиясе әгъзалары җыелма исемлекләр төзегән, исәпкә алу эшләрен алып барган һәм гаиләләрнең торак шартларын яхшырту өчен гамәлдәге законнар нигезендә аларның локаль исемлекләрен хуплаган өчен җаваплы булалар.

2 нче кушымта
Расланды
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 маендагы 409 нчы номерлы карары белән

**Иҗтимагый торак комиссиясенең составы**

| | |
|---|---|
| Хәкимуллин Р.Ф. | район Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары, комиссия рәисе |
| Фатыхов Д.З. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы, комиссия рәисенең урынбасары |
| Шумкова Л.Н. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенең торакны исәпкә алу һәм бүлү секторы мөдире, комиссия секретаре |
| Архипов В.Д. | район Советы юридик бүлеге начальнигы |
| Минаева Г.Р. | Биектау муниципаль районында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Сабитов Р.Ф. | «Техник инвентаризация бюросы» республика дәүләт унитар предприятиесенең Биектау участогы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гобәйдулин А.Р. | «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган оешмасының Казан регионара вәкиллеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Вәлиева Г.А. | «Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсе опека һәм попечительлек буенча хезмәтенең әйдәп баручы белгече |
| Миннебаев Н.Н. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы |
| Маннапова Р.А. | Биектау муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең II разрядлы өлкән белгече (килешү буенча) |
| Ганиев И.Ф. | Россия Эчке эшләр министрлыгының ЭБиПК төркеменең Биектау районы буенча оперуполномоченные, полиция капитаны |